| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕАЧАСЫРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗЕЛЕНОДОЛЬСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ АЧАСЫР АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 елның 9 октябре №16

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының хисапчылык хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 23 апрелендәге 10/2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

Хисапчылык хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын камилләштерү максатларында Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитеты **карар итә:**

1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының хисапчылык хезмәтләре хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында» 2019 елның 23 апрелендәге 10/2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Ачасыр авыл җирлеге Башкарма комитетының хисапчылык хезмәтләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары һәм оештыру турында нигезләмәнең 3 пунктын (муниципаль хезмәткәрләр вазыйфаларына кертелгән вазыйфалардан тыш) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Хисапчыларның вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Муниципаль берәмлектә халык саны | Вазыйфаның исеме, оклад (сум) | |
|---|---|---|
| | Баш хисапчы | Хисапчы |
| 3,5 меңгә кадәр кеше | 16 171 | |
| 3,5 меңнән артык кеше | 17 510 | |
| 1,9 меңнән артык кеше | | 14 935»; |

2. Әлеге карар имза салынган мизгелдән үз көченә керә һәм 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Интернет челтәренең Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре составындагы Яшел Үзән муниципаль районы мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru), шулай ук мәгълүмат стендларында: Олы Ачасыр авылы, Үзәк урамы, 46 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Олы Ачасыр авылы, Кооператив урамы, 26 йорт (авыл мәдәният йорты бинасы) урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольгә алуны үземдә калдырам.

Олы Ачасыр авыл жирлеге башлыгы М.Г. Гатиятуллин